**КАРАР**
**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл жирлегенең Төркәш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**24 ноябрь 2022 ел** **№ 01**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 1300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа зиратны өлешчә киртәләү, капка кую, инвентарь өчен будка төзү (материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Кыш көне Төркәш авылы юлларын кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Төркәш авылында урам яктыртуны тәэмин итү (энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Төркәш авылы клубы бинасына керә торган янкорма төзү (килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, кирәкле материаллар сатып алу, ташу);
- Видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (смета төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Спорт мәйданчыгын карап тору (смета төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);
- Чапкыч сатып алу;
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу);
- Елга аша басма салу (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу һәм ташу);

- Янгын куркынчсызлыгын тәэмин итү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу, ташу)

«РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә кеше 159 кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 103 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 103 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Төркәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 1300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яңа зиратны өлешчә киртәләү, капка кую, инвентарь өчен будка төзү (материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);

- Төркәш авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);

- Кыш көне Төркәш авылы юлларын кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- Төркәш авылында урам яктыртуны тәэмин итү (энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү);

- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);

- Төркәш авылы клубы бинасына керә торган янкорма төзү (килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, кирәкле материаллар сатып алу, ташу);

- Видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (смета төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Спорт мәйданчыгын карап тору (смета төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү);

- Чапкыч сатып алу;

- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу);

- Елга аша басма салу (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу һәм ташу);

- Янгын куркынчсызлыгын тәэмин итү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу, ташу)

«РИЗА» «КАРШЫ» ? »

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т. А. Котдусов